ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.09.2026 с.Старое Дрожжаное № 461

Реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, рөхсәтне гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2026 елның 4 августындагы 285-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 27 октябрендәге 416 номерлы карары (03.07.2026 № 298 редакциясендә) белән расланган Реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, рөхсәтне гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**3 пунктка** түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Вакытлыча чикләү чаралары кулланыла торган затлар исемлегенә кертелгән физик зат тарафыннан мәгълүмат-технологик һәм коммуникация инфраструктурасыннан, шул исәптән Бердәм порталдан һәм (яисә) Республика порталыннан, файдаланып, хезмәтләр күрсәтү турында гарызнамә һәм хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле башка документлар бирү рөхсәт ителми.»;

**15 пунктка** түбәндәге эчтәлекле **10 пунктча өстәргә:**

«10) Бердәм порталда физик затның вакытлыча чикләү чаралары кулланыла торган затлар исемлегенә кертелүе турында мәгълүмат булган очракта.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

Җитәкче Р.И. Мөхәммәтҗанов